# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Югары Юмья авылында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

11 ноябрь, 2025 ел №2

««Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ 3 номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, үзара салым суммасының 100 % ы күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрби хезмәткәрләре һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

2) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм;

3) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү;

4) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

5) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

6) авылы территориясен төзекләндерү;

7) традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау.

3. Әлеге карарны Оштырма-Юмья авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Оштырма-Юмья авыл җирлеге
башлыгы: С.В. Тимофеев